Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районының "Аппак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге
Советы карары белән кабул ителде
2025 елның «08» августы № 127

# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына Үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Аппак ав.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Әлки муниципаль районы**
**Аппак авыл җирлеге**
**Советы**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Совет Аппаковского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422888, ТР, Әлки районы,
Аппак авылы, Тынычлык урамы,1 й.
Тел/Факс 8 (84346) 76443

422888, РТ, Алькеевский район,
с.Аппаково, ул.Мира, д.1
Тел/Факс 8 (84346) 76443

РЕШЕНИЕ Аппак ав. КАРАР

2025 елның "08" августы № 127

Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 79-нчы номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Аппак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Аппак авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 79-нчы карары белән (29.07.2024 елның 100-нче карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Аппак авыл җирлеге территориясендә махсус җиһазландырылган стендларда игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Әлки районы, Аппак авылы, Тынычлык урамы, 1 йорт (җирле үзидарә бинасы), с. Апак, Тынычлык ур., 1 йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Аппак авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Советы Рәисе И.Х.Әбҗәббарова

СОВЕТ АППАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЬКЕЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ОГРН 1021605756810 ИНН 1606000674

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Аппак авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 127

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Аппак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:
"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".